Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

03.02.2020ел. № 2

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында» 2018 елның 27 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Чәчәкле авыл җирлеге Советы авыл җирлегенең Башкарма комитеты нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын урамда йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

- хуҗасы милкендә яки милкендә булган җир кишәрлекләре;

- кешеләр күпләп җыела торган авыл җирлеге территориясендә: буш урыннар, торак сектор һәм җәмәгать урыннары, борынлыкларда һәм поводокларда,

- балалар һәм спорт мәйданчыкларында йорт хайваннарын ирекле йөртүне тыю,

- йорт хайваннарының, урыннарда һәм гомуми кулланылыштагы территорияләрдә яшәеш продуктларын җыюны тәэмин итәргә.

- җирле үзидарә органы карары белән хайваннарны урамда йөртү өчен рөхсәт ителгән урыннардан тыш хайванны урамда йөртүгә юл куймаска.

2. Әлеге карарны Чәчәкле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Чәчәкле авыл җирлеге битендә Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spassriy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе: Ә.Н. Исмәгыйлева